**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның 3 сентябре** **№ 95**

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 44 маддәсе, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 88, 89, 90 маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”гы карар проектын (1 нче кушымта) хупларга.

2. “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар проекты турында”гы “Кама Тамагы муниципаль районы Советы карарына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе”н 2 номерлы кушымта нигезендә расларга.

3. 2018 елның 6 августында Тәмте мәдәният йорты бинасында 14.00 сәгатьтә “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча ачык тыңлаулар билгеләргә. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советының 2007 елның 29 июнендәге 29 номерлы карары белән расланган ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе нигезендә ачык тыңлаулар үткәрергә.

4. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, Октябрь урамы, 65 йорт (авыл җирлеге администрациясе бинасы);
- ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, Октябрь урамы, 50 йорт (мәдәният йорты бинасы)

һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Тәмте авыл җирлеге Башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Тәмте авыл Советы Рәисе** **И А. Зиновьев**

2018 елның 3 сентябрендәге “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”гы 95 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советы карарына кушымта

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. 14 маддәнең 8 пунктын “, гражданнар җыены” сүзләре белән тулыландырырга.

2. II бүлек. Җирле үзидарәне халык тарафыннан турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда халыкның катнашуы рәвешләрен түбәндәге эчтәлекле “гражданнар җыены” 24.1 маддә белән тулыландырырга:

“1. Гражданнар җыены җирле үзидарәне халык тарафыннан турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда халыкның катнашуы формасы булып тора.

2. Гражданнар җыены “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законда каралган очракларда һәм җирлек Советы карары белән расланган Гражданнар җыенын үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә үткәрелә.

3. 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1 маддәсендә каралган очракларда гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин:

1) составына күрсәтелгән торак пункт керә торган авыл җирлеге (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча әлеге торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертеп була торган торак пунктта);

2) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә күрсәтелгән җирлекнең чикләрен үзгәртү, күрсәтелгән җирлекнең чикләрен үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча;

3) сайлау хокукына ия җирлек халкы саны 100 дән артык кеше булса, җирле үзидарәнең вәкиллекле органы төзү, аның саны һәм вәкаләтләре вакыты турындагы мәсьәлә буенча гражданнар җыенында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гамәлгә ашырыла;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

5) авыл җирлеге составына, шәһәр эчендәге район, федераль әһәмияттәге шәһәр округы территориясе, яисә муниципаль район чикләрендә урнашкан торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

6) халык инициативасын җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча авылара территориядә урнашкан торак пунктта күрсәтү максатларында;

7) авыл халкының тыгызлыгы түбән булган территориядә урнашкан, (әгәр авыл җирлеге халкы 100 дән артмаган булса), авыл җирлеген бетерү мәсьәләсе буенча;

8) авыл торак пунктында авыл торак пункты кандидатурасын тәкъдим итү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

9) авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелә ала.

4. Гражданнар җыены җирлек башлыгы тарафыннан яисә сайлау хокукына ия, кимендә 10 кеше булган торак пункт халкы төркеме инициативасы белән чакырыла ала.

5. Җыен үткәрү инициативасына ярдәм итәргә тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия, даими яки нигездә торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санынннан 5 процент тәшкил итә, ләкин 25тән дә ким булырга тиеш түгел.

6. Җирлек башлыгы тарафыннан тәкъдим ителә торган гражданнар җыены җирлек башлыгы карары белән билгеләнә, инициатив төркем тарафыннан бирелә торган гражданнар җыены җирлек Советы карары белән билгеләнә.

7. Торак пунктта яшәүчеләр гражданнар җыеннарын үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр ителәләр, гражданнар җыеннарын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында Нигезләмә нигезендә гражданнарны кабул итүгә чыгарыла торган мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый акт проекты һәм материаллар белән алдан ук танышалар.

8. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып торалар, җирлек башлыгы тарафыннан имзаланалар һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.”

2. 23 маддәдә:

2.1. маддәнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “ачык тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар”;

2.2. 3 өлешнең 3 пунктын төшереп калдырырга;

2.3. түбәндәге эчтәлекле 3.1 өлеш өстәргә:

“3.1. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә, җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турындагы карар проектлары, рөхсәт ителгән төзелеш объектларының чик параметрларыннан кире кагуга рөхсәт бирү турындагы  карар проектлары буенча, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән башка төр файдалану мәсьәләләре буенча җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең расланган кагыйдәләре булмаганда иҗтимагый фикер алышулар яисә ачыктыңлаулар үткәрелә, аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе әлеге маддәнең 4-10 өлешләре нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагыгы законнар нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнә.”.

3. 53 маддәдә:

а) 1 өлешнең 5 пунктчасының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“җирлекнең төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә җирлек территориясен төзекләндерү эшчәнлеген оештыра;”;

б) 1 өлешнең 8 пунктчасы  2 абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

3. 83 маддәнең 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Әлеге маддәнең 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган түләүләрне кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда хәл ителә, ә 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1 маддәсенең 1 өлешенең 4.1 пунктында каралган очракларда, гражданнар җыенында хәл ителә”.